РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11 декабрь 2018 ел Буа шәһәре № 4-36

Буа муниципаль районы
Башкарма комитетының торак сәясәте
бүлеге турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр
кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнары, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турындагы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Буа муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының бүлекләре турындагы нигезләмәне раслау турында» 2015 елның 17 апрелендәге 6-47 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 1 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бүлек эшчәнлегенең предметы һәм максаты булып үзенең компетенцияләре кысаларында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү, Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары белән ачыкланган, законнар белән билгеләнгән тәртиптә бирелгән дәүләт вәкаләтләрен үтәү өлкәсендә, аерым алганда Буа шәһәрендә яшәүче гражданнарның торак хокукларын тәэмин итү өлкәсендә, идарә итү функцияләрен башкару тора.»;

1.2. 3.1 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Бүлек җитәкчесе аңа йөкләнгән бурычларга ярашлы рәвештә түбәндәгеләргә хокуклы:

- районда предприятие, оешма һәм учреждениеләрдә торак законнарының үтәлешен тикшерүне оештырырга;

- торак мәйданының билгеләнеше буенча бүленеше, чиратларның үтәлеше һәм бүлек компетенциясенә кергән башка сораулар турында кирәкле мәгълүматларны соратырга;

- Башкарма комитет җитәкчесе каравына торак мәйданнарны бүлү һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүгә кагылышлы эшләрне камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә.

Шулай ук түбәндәгеләргә:

- Башкарма комитет, аның вазифаи заты чыгарган карарлар һәм боерыкларны әзерләүдә катнашуга, шулай ук вазифаи вәкаләтләре нигезендә карарлар кабул итүгә;

- вазифаи бурычларын үтәү сәбәпле билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә, оешмаларга үтеп керүгә;

- муниципаль хезмәт вазифасы урынына калу буенча аның хокукларын һәм бурычларын билгеләүче документлар, вазифаи бурычларның үтәлеш сыйфатын бәяләү критерийлары һәм хезмәт буенча алга үсеш шартлары белән танышуга;

- профессиональ хезмәт эшчәнлеге турында бәяләмәләр һәм башка документлар белән аларны шәхси делога керткәнче, шәхси дело материаллары белән танышуга, шулай ук шәхси делога аның язмача аңлатмаларын һәм башка документларны кертүгә;

- шәхси мәгълүматлар турындагы мәгълүматларны саклауга;

- хезмәт буенча алга үсешкә, нәтиҗәләр һәм эшнең авырлыгын, квалификация дәрәҗәсен, эш стажын исәпкә алып акчалата түләүнең арттырылуына;

- вазифаи бурычларны башкару өчен оештыру-техник шартлар белән тәэмин ителешкә;

- хезмәт өчен түләүгә һәм хезмәт законнары, муниципаль хезмәт турындагы законнар һәм хезмәт килешүе (контракт) нигезендә башка түләүләргә;

- ял көннәрен һәм эшләми торган бәйрәм көннәрен бирү белән, эш (хезмәт) вакытын нормаль дәвамлылыкта билгеләү белән тәэмин ителгән ялга, шулай ук ел саен түләнә торган отпускка;

- вазифа бурычларын башкару өчен кирәкле мәгълүмат һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә алуга, шулай ук җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе эшчәнлеген камилләштерү турында тәкъдимнәр кертүгә;

- үз инициативасы буенча вакант муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыруга конкурста катнашуга;

- муниципаль хокукый акт нигезендә, җирле бюджет чаралары исәбенә өстәмә профессиональ белем алуга;

- үзенең шәхси мәгълүматларын саклауга;

- үзенең шәхси делосындагы барлык материаллар белән, профессиональ хезмәт эшчәнлеге турында бәяләмәләр һәм башка документлар белән аларны шәхси делога керткәнче танышуга, шулай ук шәхси делога аның язмача аңлатмаларын кертүгә;

- үзенең компетенциясе кысаларында аның гаризасы буенча хезмәт тикшерүен үткәрүгә;

- муниципаль хезмәттә үзенең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга, шул исәптән алар бозылган очракта судка шикаять бирергә;

- федераль законнар нигезендә медицина иминиятенә;

- үзенең гомере һәм сәламәтлегенә һәм үзенең гаиләсе әгъзалары гомере һәм сәламәтлегенә, шулай ук аның милкендә булган милеккә дәүләт яклавына;

- үзенең хокукларын, социаль-икътисади һәм профессиональ мәнфәгатьләрен яклау өчен һөнәри берлекләр төзү хокукын да исәпкә алып, берләштерүгә;

- хезмәт законнары нигезендә индивидуаль хезмәт каршылыкларын карауга, муниципаль хезмәттә үзенең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга, шул исәптән алар бозылган очракта судка шикаять бирергә;

- Россия Федерациясе законнары нигезендә пенсия белән тәэмин ителүгә.»;

1.3. 3.11 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.11 «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турындагы кодексы белән билгеләнгән чикләүләрне үтәргә, хезмәт тәртибе бурычларын һәм таләпләрен башкарырга, тыюларны бозмаска.»;

1.4. 3.13 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.13 Устав, Нигезләмә һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турындагы кодексы нигезендә башка муниципаль хокукый актлар, вазифаи инструкцияләр белән билгеләнгән бурычларны башкарырга.».

2. Әлеге Карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы,<br>Буа муниципаль районы<br>Советы рәисе М.А. Җәббаров